| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.06.2022 Баулы шәһәре №108

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2021 елның 25 декабрендәге үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү һәм терлекчелек продукциясен җитештерү күләмнәрен Баулы муниципаль районы территориясендә сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү исәбенә арттыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү» муниципаль программасын расларга (алга таба – Программа).

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына, Баулы муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, төзелеш материаллары (шлакоблоклар, ком, гравий һ.б.) сатып алуга бюджеттан тыш акчалар, иганәчеләр акчаларын бүлеп бирүне карарга.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына, муниципаль район оешмалары һәм хезмәтләре җитәкчеләренә, Баулы муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә Программаны гамәлгә ашыру чараларын оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 10 июнендәге
108 номерлы
карары белән расланган

«2022-2025 елларга
Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районының
шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү»

муниципаль программасы

Баулы шәһәре – 2022 ел

I. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программа эшләү өчен нигезләр | - Россия Федерациясе Граждан кодексы;<br>- “Шәхси ярдәмче хуҗалык турында” 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;<br>- «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 193-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән аерым юнәлешләр буенча дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 елның 31 маендагы 397 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>- «Татарстан Республикасы халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү концепциясен раслау турында» 2006 елның 30 мартындагы 136 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| Программа заказчысы | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге, Баулы муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |

| | |
|---|---|
| Программа максатлары | Халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү өчен уңай шартлар тудыру, авыл территорияләрен үстерү, тормыш дәрәҗәсен яхшырту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче гражданнар мәшгульлеген һәм керемнәрен арттыру, Баулы муниципаль районы халкын азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту, хуҗалыклар санын арттыру |
| Программа бурычлары | - шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүне тәэмин итү һәм аларның керемнәрен арттыру;<br>- социаль шартларны яхшырту һәм авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү;<br>- Баулы муниципаль районының икътисадый актив авыл халкының мәшгульлеген арттыру, авыл халкының мәшгульлеген киңәйтү, аның керемнәрен, тормыш дәрәҗәсен һәм матди хәлен күтәрү;<br>- Баулы муниципаль районы халкын азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитешлерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе белән Баулы муниципаль районы азык-төлек базарын тутыруны яхшырту;<br>- халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына ярдәм итүдә җирле үзидарәнең ролен күтәрү;<br>- авыл хуҗалыгы продукциясенең артык өлешен сатуга ярдәм итү, шул исәптән муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар һәм тәэмин итүләр оештыру юлы белән. |
| Программа чараларын башкаручылар | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, Баулы муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, авыл җирлекләре башлыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2022-2025 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2022-2025 елларда Программа чараларын үтәүгә бюджет чыганаклары исәбенә 711,0 мең сум күләмендә финанс чыгымнары, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклар, иганә акчалары планлаштырыла.<br>Күрсәтелгән чыганаклардан бирелә торган акчалар күләме фараз характерында була һәм, программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә төгәлләштерүне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның Еллар буенча бүленгән көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны тулы күләмдә гамәлгә ашыру 2025 ел ахырына ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- Баулы муниципаль районы халыкы терлекләренең баш саны (эре мөгезле терлекләрнең) арту;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыклар һәм Баулы муниципаль районының гаилә фермалары тарафыннан терлекчелек продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыру;<br>- Программа ярдәме белән үз хуҗалыкларын үстерү проектларын гамәлгә ашырган шәхси ярдәмче хуҗалыкларның санын арттыру - кимендә 15 берәмлеккә;<br>- сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлегенең баш санын 2021 елдагы күрсәткечтән киметмәү һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт юнәлешендәге эре мөгезле терлекләр баш санын 2021 елга караганда 5%ка арттыру. |

## II. Гомуми нигезләмәләр

Авыл хуҗалыгы илкүләм икътисадның мөһим өлкәсе булып тора, агросәнәгать комплексының үзәк звеносын тәшкил итә.

Республика аграр сәясәте кысаларында федераль һәм республика максатчан программалары гамәлгә ашырыла.

Бюджет ярдәме ысуллары максатчанрак кулланыла башлады, бюджет акчалары исәбеннән процент ставкаларының бер өлешен субсидияләү нигезендә кредит бирү ысуллары камилләштерелде, авыл хуҗалыгы җитештерүен һәм азык-төлек базарын дәүләт тарафыннан җайга салу ысулларын куллану киңәйде.

Әмма, күрелгән чараларга карамастан, районның авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм шәхси хуҗалыкларда эре мөгезле терлекләрнең баш саны кимүгә таба бара, продуктивлыкның аерым күрсәткечләр дәрәҗәсе түбән.

Агросәнәгать комплексында эшләүче халык саны кими, авыл торак пунктларында эшсезләр саны арта.

Районда авыл хуҗалыгын үстерүнең тискәре факторларына түбәндәгеләр керә:

а) базарга кагылышлы - авыл хуҗалыгы продукциясенә, сәнәгать продукциясенә һәм энергия чыганакларына бәяләр диспаритеты, азык-төлек импортын арттыру шартларында авыл хуҗалыгы продукциясенә сатып алу бәяләренең түбән булуы;

б) финанс-икътисадый - авыл хуҗалыгын үстерүгә ярдәм итүгә һәм авылны социаль төзекләндерүгә җибәрелә торган муниципаль район бюджеты акчаларының күләме чикле булу, кредит ресурсларыннан файдалану мөмкинлеге булмау;

в) социаль - хезмәткә сәләтле халыкның читкә китүе (халыкның картаюы), авыл хуҗалыгы кадрлары кытлыгы.

Баулы муниципаль районында терлекчелек буенча җитештерү күрсәткечләре кимүе кайбер шәхси ярдәмче хуҗалыкларның терлекчелекнең башка төрләренә күчүе белән бәйле, алар эре мөгезле терлекне бетерделәр (кәҗәләр, кошлар үрчетә башладылар).

Терлекчелектә вәзгыятьнең начарлануына китергән төп сәбәпләр булып түбәндәгеләр тора: хезмәткә сәләтле халыкның башка төбәкләргә китүе, азык базасының кыйммәт булуы һәм терлекләрнең үзкыйммәте югары булу.

Халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, авыл территорияләрен үстерү, шулай ук халыкны азык-төлек белән тәэмин итү бурычларын хәл итү өчен илдә стратегик социаль-икътисадый үзгәртеп корулар барышында авыл территорияләренең

урынын һәм ролен яңадан карауны, шул исәптән авыл территорияләрен үстерү өчен алшартлар тудыру буенча түбәндәге чаралар күрүне таләп итә:

- тормыш эшчәнлеге шартларының уңайлылыгы дәрәҗәсен күтәрү;

- авыл халкының торак шартларын яхшырту;

- авыл җирлегендә хезмәтнең абруен күтәрү һәм җәмгыятьтә авыл тормышына уңай караш тәрбияләү;

- демографик хәлне яхшырту;

- авыл җирлегендә җирле үзидарәне һәм граждан җәмгыяте институтларын үстерү.

Икътисадый үзгәртеп корулар барышында аграр өлкәдә җитештерү потенциалы формалашты һәм планлы рәвештә үсә бара, аның алга таба үсеше авыл территорияләрен комплексы үстерүнең тотрыклылыгына, икътисадый үсешнең кеше факторын активлаштыруга бәйле. Авыл территорияләренең социаль-икътисадый потенциалын үстерү, әлеге процесска юл бирү дәүләт аграр сәясәтенең стратегик бурычы булып тора, бу «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» Федераль законда беркетелгән.

## III. Программаның максаты һәм бурычлары

Программа максаты - Халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү өчен уңай шартлар тудыру, авыл территорияләрен үстерү, тормыш дәрәҗәсен яхшырту, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче гражданнар мәшгульлеген һәм керемнәрен арттыру, Баулы муниципаль районы халкын азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту, хуҗалыклар санын арттыру.

Программаның төп бурычлары:

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүне тәэмин итү һәм аларның керемнәрен арттыру;

- социаль шартларны яхшырту һәм авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү;

- Баулы муниципаль районының икътисадый актив авыл халкының мәшгульлеген арттыру, авыл халкының мәшгульлеген киңәйтү, аның керемнәрен, тормыш дәрәҗәсен һәм матди хәлен күтәрү;

- Баулы муниципаль районы халкын азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитешлерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе белән Баулы муниципаль районы азык-төлек базарын тутыруны яхшырту;

- халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына ярдәм итүдә җирле үзидарәнең ролен күтәрү;

- авыл хуҗалыгы продукциясенең артык өлешен сатуга ярдәм итү, шул исәптән муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар һәм тәэмин итүләр оештыру юлы белән.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру юлы белән хәл ителә торган проблемалар характеристикасы һәм анализы

2021 елда барлык категория хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 2 844,2 млн. сум тәшкил иткән, үсеш темпы - 83,4%.

Муниципаль районда авыл хуҗалыгы белән 10 эре хуҗалык һәм 46 вак крестьян-фермер хуҗалыгы шөгыльләнә.

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм КФХ буенча тулаем продукция 1 308,5 млн. сум тәшкил итте, шәхси ярдәмче хуҗалыклар буенча - 1 535,7 млн. сум.

Районда авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданы 70 700 гектар тәшкил итә, шуларның 52 225 гектары сөрү җире.

Барлык төр хуҗалыкларда 2021 елда 21,5 мең тонна сөт җитештерелгән (шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларда - 6,4 мең тонна), 2,9 мең тонна ит җитештерелгән (шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларда - 1,1 мең тонна).

2021 елда район хуҗалыкларында барлык авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан акчалата керем 817,7 млн. сумнан артык тәшкил иткән, бу алдагы ел белән чагыштырганда 21,7%ка кимрәк.

Баулы районының авыл хуҗалыгы өлкәсендә 630 кеше хезмәт куя. 2021 елда айлык уртача хезмәт хакы 26 745 сум тәшкил иткән, 2020 ел дәрәҗәсенә карата үсеш темпы - 114,7%.

Район территориясендә 6 064 шәхси ярдәмче хуҗалык исәпләнә, эре мөгезле терлекләр саны - 4 100 (шул исәптән 1 560 баш сыер), 161 дуңгыз, сарык һәм кәҗәләр - 4 790, кош-корт - 13500.

Авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем күләме 54% тәшкил итә. Соңгы дистә елда халыкны азык-төлек һәм финанс белән тәэмин итүдә шәхси ярдәмче хуҗалыкның роле шактый әһәмиятле булды. Шул ук вакытта, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен реформалаштыруга бәйле рәвештә, күмәк хуҗалыклар һәм шәхси хуҗалыклар арасындагы аерманы исәпкә алып, төрле шартларда шәхси ярдәмче хуҗалыкларның характеры һәм мөмкинлекләре шактый аерыла.

Шәхси ярдәмче хуҗалык тотучылар үзләренең хуҗалык эшчәнлеге процессында фермерлар өчен актуаль булган проблемалар белән очрашалар.

Аларны гомумиләштереп, вак авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә хезмәт күрсәтү инфраструктурасының үсмәгәнлеге буларак бәяләргә мөмкин:

- матди-техник ресурслар, шул исәптән авыл хуҗалыгы техникасы, инвентарь, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел эшкәртү өчен җайланмалар һәм башкалар белән тәэмин итү;
- җитештерелгән продукцияне сату өчен отышлы чорга кадәр саклау (склад мәйданнарын арендалау, үз товар складларын төзү);
- авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел эшкәртү;
- җитештерелгән продукцияне сату.

Авылда хезмәткә сәләтле халык саны кимү, аның картаюы, шулай ук яшьләр тарафыннан ярдәм булмау һәм терлекләрне тотуның гамәлдәге технологиясе, эре мөгезле терлекләрне тотуга югары чыгымнар, сөткә сатып алу бәяләре түбән булу - болар барысы да Баулы муниципаль районының шәхси-ярдәмче хуҗалыкларында эре мөгезле терлекләр баш саны кимүгә китерә.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү һәм эре мөгезле терлекләр санын арттыру максатларында җирле бюджеттан кече фермалар төзү һәм саву аппаратлары сатып алу өчен финанс чаралары бүлеп бирелә. Шулай ук республика бюджетыннан субсидия алуда консультатив ярдәм күрсәтелә. 2018-2021 елларда Татарстан Республикасы бюджеты субсидияләреннән 12 шәхси ярдәмче хуҗалык файдаланды, субсидия алган мини-фермаларда эре мөгезле терлекләр саны 423 баш тәшкил итә. 2018 елдан башлап мини-фермалар төзү программасында катнашучыларга һәм 3 һәм аннан да күбрәк сыерлы шәхси ярдәмче хуҗалыклар башлыкларына җирле бюджеттан 45 саву аппараты, 28 шәхси ярдәмче хуҗалыкларга мини-фермалар төзү өчен 1100 керамзитобет блогы бирелгән.

## V. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программаны гамәлгә ашыру 2022 - 2025 еллар дәвамында ел саен гамәлгә ашырылачак. Программа ел нәтиҗәләре буенча районның һәм авыл җирлекләренең социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләрен исәпкә алып ел саен төзәтелә ала.

## VI. Программа чараларын нигезләү һәм аларны ресурслар белән тәэмин итү

Авыл хуҗалыгы җитештерүенең динамикалы икътисадый үсешен, авыл халкының мәшгульлеген тәэмин итүдә хуҗалык итүнең кече формаларының ролен күтәрү һәм аның тормыш дәрәҗәсен яхшырту өчен авыл хуҗалыгында, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне һәм эшкәртүне оештыру өлкәсендә кече эшкуарлык формаларын алга таба үстерү күздә тотыла. Шуңа бәйле рәвештә, Программаны гамәлгә

ашыру кысаларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга муниципаль ярдәм чараларын алга таба үстерү күздә тотыла:

а) терлекчелек продукциясен җитештерүне субсидияләү;

б) авыл кредит, сатып алу, иминият һәм башка куллanучылар кооперативларын булдыруны стимуллаштыру;

в) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөтнең товарлыгын арттыру;

г) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны терлек азыгы белән тәэмин итү;

д) кече фермалар төзегәндә гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына чыгымнар өлешен каплау;

е) үз хуҗалыгында 3 һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны һәм гаилә фермаларын (кече фермаларны) индивидуаль саву җайланмалары белән тәэмин итү.

Программа чаралары исемлеге әлеге Программага 1 нче кушымтада бирелгән.

Программа чараларын үтәүгә бюджет акчалары, шулай ук бюджеттан тыш акчалар һәм иганә акчалары хисабына финанс чыгымнары планлаштырыла. Күрсәтелгән чыганаклардан бирелә торган акчалар күләме фараз характерында була һәм, программа чаралары исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә төгәлләштерүне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш.

## VII. Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре һәм максатчан индикаторлар (күрсәткечләр)

Программа чаралары комплексын гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

а) авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү;

б) терлекләрнең һәм кошларның продуктивлыгын арттыру нигезендә терлекчелек продукциясен арттыру;

в) шәхси ярдәмче һәм крестьян-фермер хуҗалыгының финанс хәлен ныгыту;

г) икътисадның башка тармакларына карата авыл хуҗалыгында эшләүче керемнәрне арттыру;

д) авыл халкының мәшгульлеген арттыру.

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү» муниципаль программасы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- районның азык-төлек иминлеген тәэмин итүдә, товар авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыруда шәхси ярдәмче хуҗалыкларның ролен арттырырга;

- Программа ярдәме белән үз хуҗалыкларын үстерү проектларын гамәлгә ашырган шәхси ярдәмче хуҗалыклар санын арттырырга (кимендә 15 берәмлеккә);

- сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлегенең баш санын 2021 елдагы күрсәткечтән киметмәү һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт юнәлешендәге эре мөгезле терлекләр баш санын 2021 елга караганда 5%ка арттыру.

Программаның максаты һәм бурычларын хәл итүгә ирешү әлеге Программага 2 нче кушымтада китерелгән максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) белән бәяләнә.

Әлеге күрсәткечләрнең динамикасы башкарылган чараларның нәтиҗәлелеген күрсәтә.

## VIII. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру механизмы азык-төлек иминлеге торышын яхшырту, Баулы муниципаль районы авыл халкының тормыш сыйфатын яхшырту, терлекләрнең баш санын арттыру һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле авыл хуҗалыгы җитештерүен формалаштыруга юнәлдерелгән Программаның чараларын башкаручыларның координацияле гамәлләреннән гыйбарәт.

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрә һәм бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны контрольдә тота.

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәләре Баулы муниципаль районы Башкарма комитетында Баулы муниципаль районы авыл җирлекләре Башлыклары катнашында ел саен карала һәм тикшерелә.

Программаны гамәлгә ашыру турында ел саен Баулы муниципаль районы башлыгына хисап бирелә.

## IX. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең түбәндәге социаль-икътисадый нәтиҗәләрен алырга мөмкинлек бирәчәк:

- конкурентлык мохитен үстерү;
- авыл территорияләрен үстерү һәм үзләштерү өчен шартлар тудыру;
- яңа эш урыннары булдыру;

- халыкны сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү.

Программаны гамәлгә ашыру шулай ук түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- тәэмин итү-сату һәм эшкәртү өлкәләрендә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү;

- авыл җирлегендә яшәүнең гамәлдәге системасын үстерү һәм саклап калу өчен шартлар тудыру;

- гаилә бизнесына ярдәм итү һәм авыл җирлегендә традицион тормыш рәвешен саклап калу рәвешендә социаль нәтиҗә алу.

Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыклары үсешенә Программаның гомуми бәяләмәсе авыл хуҗалыгы өлкәсендә стратегик максатларга ирешүгә, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыруга һәм аның конкуренциягә сәләтлелеген арттыруга, авыл халкының үзмәшгульлеген һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә, Баулы муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре территорияләрен үстерүгә ярдәм итәчәк чараларын гамәлгә ашыру юлы белән билгеләнә.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә тактик һәм стратегик бурычларны хәл итү дәрәҗәсен чагылдыра торган күрсәткечләр – шәхси ярдәмче хуҗалыкларның санын арттыру һәм Баулы муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыру.

Программаны гамәлгә ашыру авылда кече хуҗалыкларны үстерү өчен алшартлар тудырачак.

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче
хуҗалыкларын үстерү» муниципаль
программасына 1нче кушымта

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү»
муниципаль программасының программа чаралары исемлеге

| № п/п | Чара исеме | Башкаручылар | Финанслау чыганагы | Финанслау суммасы еллар буенча мең сум. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел фараз | 2024 ел фараз | 2025 ел фараз | барлыгы |
| 1. Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүне (ЛПХ) стимуллаштыру | | | | | | | | |
| 1.1. | 3 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга саву аппаратлары бирү | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - БМР башкарма комитеты), Баулы муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (алга таба - БМР авыл хуҗалыгы-идарәсе) (килешү буенча) | җирле бюджет | 480,0 | - | - | - | 480,0 |
| 1.2. | Сөт юнәлешендәге кече фермалар төзүдә матди ярдәм күрсәтү | БМР башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе (килешү буенча) | җирле бюджет | 231,0 | - | - | - | 231,0 |
| 1.3. | Гаилә фермалары төзүдә, шул исәптән җир кишәрлекләрен һәм биналарны рәсмиләштергәндә, | БМР башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе | не требуется | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярдәм күрсәтү юлы белән авылда эшкуарлыкны үстерүгә консультатив ярдәм күрсәтү | (килешү буенча) | | | | | | |
| 1.4. | Яшь фермерларга дәүләт ярдәменә грантлар алуда һәм (яисә) бер мәртәбә ярдәм күрсәтүдә, шулай ук гаилә фермаларын үстерүдә консультатив ярдәм | БМР башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе (килешү буенча) | кирәкми | - | - | - | - | - |
| 2. Авыл халкын һәм авыл учреждениеләрен социаль төзеклəндерү һәм аларга ярдәм итү | | | | | | | | |
| 2.1. | Авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрү | БМР башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе (килешү буенча) | кирәкми | - | - | - | - | - |
| 2.2. | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат җиткерү | БМР башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе (килешү буенча) | кирәкми | - | - | - | - | - |
| Барлыгы: | | | | 711,0 | - | - | - | 711,0 |

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче
хуҗалыкларын үстерү» муниципаль
программасына 2нче кушымта

2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү буенча төп күрсәткечләр (индикаторлар)

| № п/п | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2021 ел факт | 2022 ел бәя | 2023 ел фараз | 2024 ел фараз | 2025 ел фараз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны (ШЯХ) | бер. | 6064 | 6064 | 6064 | 6064 | 6064 |
| 2. | Крестьян-фермер хуҗалыклары саны (КФХ) | бер. | 53 | 53 | 55 | 56 | 57 |
| 3. | Эре мөгезле терлекләр саны, барлыгы: | бер. | 4100 | 4240 | 4320 | 4410 | 4490 |
| | шулардан сыерлар | бер. | 1560 | 1580 | 1595 | 1615 | 1640 |
| 4. | атлар | бер. | 360 | 362 | 365 | 365 | 365 |
| 5. | Сарыклар һәм кәҗәләр | бер. | 4790 | 4885 | 4982 | 5032 | 5040 |
| 6. | Кошлар | бер. | 13500 | 14500 | 15000 | 15500 | 16500 |
| 7. | Умарталыклар | бер. | 3650 | 3675 | 3700 | 3720 | 3750 |
| 8. | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда (ШЯХ) сөт җитештерү күләмнәрен арттыру | литр | 6430 | 6740 | 7064 | 7417 | 7780 |
| 9. | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда (ШЯХ) ит җитештерү күләмнәрен арттыру | тонна | 1140 | 1150 | 1160 | 1170 | 1180 |
| 10. | 3 һәм аннан да күбрәк сыер тотучы шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны | бер. | 160 | 162 | 165 | 168 | 171 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (ШЯХ) | | | | | | |